ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

21 01 2020 г. № 22

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 23 октябрендәге 648 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5.8 пункты нигезендә карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 23 октябрендәге 648 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1-нче кушымтада 12-нче биттә (Б5 фрагменты) 186, 185, 192-нче урыннарны, 25-нче биттә (Г3 фрагменты) 130, 131-нче урыннарны, 26-нчы биттә (Г4 фрагменты) 227-нче урынны, 31-нче биттә (Д9 фрагменты) 215, 216, 217, 218-нче урыннарны, 33-нче биттә (Е9 фрагменты) 208-нче урынны, 42-нче биттә (К3 фрагменты) 223-нче урынны, 45-нче биттә (Л2 фрагменты) 211, 212, 213, 214, 224-нче урыннарны төшереп калдырырга;

карарга 2-нче кушымтада 130, 131, 185, 186, 192, 208, 211, 212, 213, 214, 215, 216, 217, 218, 223, 224, 227-нче юлларны төшереп калдырырга.

2. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» МКУ (Мингалиева А.Р.), әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 90 көннән дә соңга калмыйча, «Арт-Мастер» ҖЧҖ, «РК Цвет» ҖЧҖ реклама конструкцияләре хуҗаларына, кушымта итеп бирелә торган исәп-хисап нигезендә, җирле бюджет акчалары исәбеннән түләнергә тиешле компенсацияне башкарырга (кушымта).

3. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.И. Беляевка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «21» гыйнвар
22-нче номерлы карарына
кушымта

«Арт-Мастер» ҖЧҖ, «РА «Цвет» ҖЧҖ реклама конструкцияләре хуҗаларына компенсация түләүне хисаплау

| № | Реклама конструкциясе хуҗалары | Реестр номеры | Шартнамә срогы | Компания тарафыннан түләнгән гомуми сумма, сум | Файдаланган көннәр саны | Кире кайтару суммасы, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | «Арт-Мастер» ҖЧҖ | 192 | 07.09.2018 - 07.09.2028 (10 ел; 3653 көн) | 683 415,90 | 306 (2019 елның 10 июленә кадәр) | 626 168, 36 |
| 2 | «Арт-Мастер» ҖЧҖ | 185 | 13.08.2018 - 13.08.2028 (10 ел; 3653 көн) | 248 936,05 | 351 (2019 елның 30 июленә кадәр) | 225 016, 93 |
| 3 | «РА «Цвет» ҖЧҖ | 186 | 05.09.2018 - 05.09.2028 (10 ел; 3653 көн). | 226 305,50 | 308 (2019 елның 10 июленә кадәр) | 207 224, 72 |
| Барлыгы | | | | | | 1 058 410,01 |